# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

## КАРАР

№ 33 05.02.2021ел

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының «Өченче зат хокукларыннан ирекле (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән , кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга (шул исәптән ташламалы аренда түләве ставкалары буенча) озак сроклы нигездә (шул исәптән ташламалы ставкалар буенча) файдалануга бирү өчен билгеләнгән, муниципаль мөлкәтне арендага бирү тәртибе һәм шартлары турында» 2017 елның 22 маенда кабул ителгән 103 номерлы карарына (ТР Аксубай муниципаль районы Советының 17.05.2019 ел, 199 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 8 июнендәге 169-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 1 һәм 2 статьяларына үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә, ярдәм алучы кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрын формалаштыру максатларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының «Өченче зат хокукларыннан ирекле (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән , кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлар*ына ярдәм* инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга (шул исәптән ташламалы

аренда түләве ставкалары буенча) озак сроклы нигездә (шул исәптән ташламалы ставкалар буенча) файдалануга бирү өчен билгеләнгән, муниципаль мөлкәтне арендага бирү тәртибе һәм шартлары турында» 2017 елның 22 маенда кабул ителгән 103 номерлы карарына (ТР Аксубай муниципаль районы Советының 17.05.2019 ел, 199 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 1.4. пунктта түбәндәге эчтәлекле 3) абзац өстәргә:

«3) үзмәшгуль эшләүчеләр буларак теркәлгән физик затлар».

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatar.ru)урнаштырырга һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының бюджет, салымнар һәм финанслар, җирле җыемнар, инвестицияләр һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы Советы
Совет Рәисе

К.К.Гилманов